ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУШМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОШМАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.01.2020 Кошман ав. № 2

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең 2028 елга кадәр чорга су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу схемаларын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» Федераль законнары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу схемалары турында» 2013 елның 5 сентябрендәге 782 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарга кушымта итеп бирелүче су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу схемаларын расларга.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 29 сентябрендәге 12 номерлы «Кошман авыл җирлегенең су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу схемаларын раслау турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмати – телекоммуникация челтәрендәге веб-адресы буенча http://kushman-kaybici.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кайбыч муниципаль районы
Кошман авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Р. Сафина